РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ АХМЕТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423030 д. Ахметово ул.Центральная дом 48
телефон 8(84345)28274

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘХМӘТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423030 Әхмәт авылы, Үзәк ур. 48 йорт
телефон 8(84345)28274

---

30 октябрь 2019 ел № 5

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Әхмәт авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2019 елның 14 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Әхмәт авылы, Үзәк урам, 48 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2019 елның 14 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Әхмәт авылы, Үзәк урам, 48 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аеруга сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарыла.
4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.
5. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«2020 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Әхмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган

кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү.

«ӘЙЕ» «ЮК».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Шәйхетдинов Р.Х.